БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
6 февраль 2025 ел

**КАРАР**
№ 299

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданы» исеме турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2010 елның 2 апрелендәге 178 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданы» исеме турындагы Нигезләмәгә (2013 елның 27 апрелендәге 163 номерлы, 2013 елның 30 маендагы 167 номерлы, 2015 елның 17 апрелендәге 275 номерлы, 2017 елның 14 июнендәге 85 номерлы, 2019 елның 31 маендагы 192 номерлы, 2020 елның 24 августындагы 261 номерлы, 2021 елның 07 июнендәге 59 номерлы карарлар нигезендә расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 1 бүлектәге «Гомуми нигезләмәләр»нең 1.1 пунктына «һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә яшәүчеләргә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә буенча гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, законлылык һәм хокук тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы Рәисе — Р. Р. Нотфуллин